# КАРАР

**25 ноябрь, 2020 ел** **№1**

**Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Пычак авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 25 ноябрендә сәг. 19.00 дә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар, студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Пычак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Псәк авылының Мәхмүт Яхин урамында, вак таш җәеп, чокырларны ямау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамында машина-трактор паркыннан алып Пычак урта гомуми белем бирү мәктәбенә кадәр юлны асфальтлау;
- Пычак авылы артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;
- Пычак авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту, җәйге чорда территорияне чабу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- янгын шланглары, гидрантлар, колонкалар сатып алу;
- янгын коеларын, краннарны сатып алу һәм урнаштыру.
- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамында машина-трактор паркыннан алып Пычак урта гомуми белем бирү мәктәбенә кадәр юлда чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт);
- чишмәләрне төзекләндерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 119 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 64 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен җыенда катнашкан 64 кеше тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде;

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Кукмара шәһәрендә халык җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип таныргa.

Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар, студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль

районы Пычак авыл җирлегенең Пычак авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Псәк авылының Мәхмүт Яхин урамында, вак таш җәеп, чокырларны ямау, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамында машина-трактор паркыннан алып Пычак урта гомуми белем бирү мәктәбенә кадәр юлны асфальтлау;
- Пычак авылы артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;
- Пычак авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту, җәйге чорда территорияне чабу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- янгын шланглары, гидрантлар, колонкалар сатып алу;
- янгын коеларын, краннарны сатып алу һәм урнаштыру.
- Пычак авылының Мәхмүт Яхин урамында машина-трактор паркыннан алып Пычак урта гомуми белем бирү мәктәбенә кадәр юлда чокырларны төзекләндерү (ямочный ремонт);
- чишмәләрне төзекләндерү?»

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл
җирлеге башлыгы Г.Ш.Нәфыйков